


ЧАЯН

ISSN 0134-384

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ * МАЙ * 2016 * КАЗАН



Илдар НӘФИЕВ



Аннан-Моннан
ИНФОРМ
СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

- Президент белән туры элемтә барган вакытка чаклы Юлсыз урамындагы юлны төзекләндерделәр. Чарасызлыктан шул урамда яшәүчеләр сораулары ничегрәк итеп бирергә кирәклеген дә аңламый калдылар.
- «Восточный» космодромын белгечләр кабатланмас бердәнбер дип атады: чөнки утыртулар монда җибәргәнче үк башкарыла.
- Рәсәй, булган җитешсезлекләргә карамастан, әле һаман юллардагы чокыр-чакырлар буенча алдынгы сафларда бара.
- НАТО белән якынлашуга беренчеләрдән булып Рәсәй авиациясе очты.
- Рәсәйнең югары уку йортларында 100 мең бюджет урынын кыскартачаклар. “Акыллы башлар күбәйде”, – дип аңлаттылар Мәгариф министрлыгында.
- Озак кына тәнәфестән соң фитнес-заллар эшли башлады — бакчадагы биләмәләр.
- Канализация шартлаганнан соң, беренчеләрдән булып анда “Аннан-моннан информ” хәбәрчесе пәйда булды.
- ЖКХ тармагы керем буенча өченче урынны яулады. Беренчелектә – наркотиклар сәүдәсе һәм фәхеш.
- Идарә компанияләре һава шартлары белән идарә итүнең җаена төшеләр: җылы бирүне туктаталар — урам суына, бирәләр — һава торышы җылыга үзгәрә.
- Алтмыштан соң яшәүче кешеләрне Пенсия фондында “халыкның үч алучылары” дип атыйлар.
- Инглиз галимнәре, тоз молекулалары кыяр молекулалары белән яхшы яраклаша дигән фикергә килгәннәр.
- Европа хокук саклаучылары кесә телефоннарының чукраклар хокукын бозуына протест белдергәннәр.
- Суд приставы, сыра сата торган барга кереп, бурычлының мөлкәтен барлап чыккан.
- Селекционерлар “үбешү өчен яңа сарымсак” уйлап тапканнар.
- Юлаучы көтмәгәндә-уйламаганда марафон йөгергән.
- Футбол уены вакытында кырга көчек йөгереп чыккан һәм команданың берсенә җиңү китергән.



Виталий ФЕОКТИСТОВ



ШОМБАЙ
болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Күптән түгел халык өчен янып йөрүче депутатларның һәм аларның гаилә әгъзаларының узган ел буенча керемнәре турында мәгълүматлар басылып чыкты. Алар өчен шатландым – ичмасам, кем булса да баеган икән. Үзем булмаганга кәефем кырылды. Нишлисең бит, кризис... Ә депутатларның үзләреннән дә баерак булып чыккан хатыннары өчен шатландым...


А. ГАТИНА

ТҮБӘН КАМА

– Мин нишләптер аңлый алмыйм, – диде Шомбай ага, укучыбызның хатын укып чыккач. **– Бай хатын булыр өчен депутат хатыны булырга кирәкме, әллә депутат хатыны булыр өчен үзеңә бай булырга кирәкме?**



Валентин ДРУЖИНИН



Соры күзле чибәр Кәҗәмөгез назлы Кыз эзли.

Йорт янып бетте, ат качып китте. Ә син һаман юк та юк...

Исәнмесез! Минем исемем Фәридә. Миңа 23 яшь. Әгәр сезне минем серле хатым кызыксындырган икән, языгыз.

Зарарлы гадәтләре булмаган сау-сәламәт җиңел гәүдәле әби (62/170/74) дәртле, кайгыртучан һәм тугры ир эзли.

Мәхәббәт уты кабызып җибәр! Һичьюгы, шырпысын сыз!

Ир кеше эзлим. Әзер гаилә: чибәр хатын, бала һәм теща.

Мин сөйкемле, тәрбияле, эчмим, тартмыйм, эшләмим.

Яшь егет тормыш иптәше булырдай урта яшьтәге бай бизнесмен хатын эзли.

(танышу белдерүләреннән)



Валерий ТАРАСЕНКО



Валентин ДУБИНИН

СОҢАРГАН ӨМЕТЛӘР

Җор телле берәү безнең депутатларга законнар урынына тынычландыру даруы кабул итәргә кирәк, дип әйткән, ди. Бу шулайдыр да. Аларның соңгы шаулы тәкъдимнәрен искә алу гына җитә: Кремльне ак төскә буярга, биек үкчәләр һәм спорт аяк киемнәрен тыярга, 100 сумлык купюраларда сурәтләнгән Аполлонның артык әгъзаларын алып ташларга, гражданнарны сарымсак ашаудан сакларга, шикле элемтәләр өчен штраф салырга, белгечлек буенча эшләмәүне тыярга һ. б. Сайлаучыларны үзләренең фантазиясе белән таң калдырган депутатларның башына язга таба акыллы уйлар килгәли башлый. Мәсәлән, балачаклары Бөек Ватан сугышы елларына туры килгәннәргә льготалар кертү турында. Алар бу тәкъдимне даими рәвештә кертәләр һәм шулай ук кире дә кагалар.

Быел да гадәти кагыйдәдән читләшмәделәр. Хезмәт һәм социаль политика комитеты чираттагы тапкыр закон проектын кабул итмәве турында белдерде. Имеш, һәр федерация субъекты үзенең сугыш чоры балалары өчен үзе бирәр нәрсә уйлап чыгарсын. Аларның күбесе – инвалидлар, хезмәт ветераннары, алар барыбер нинди дә булса социаль ярдәм чарасыннан файдалана. Нигә артыгын түләргә? Һәм ниһаять төп дәлил – өстәмә льготалар өчен акча юк һәм булмаячак та. Карагыз, алар ил буенча 12 миллион, моңа нинди алтын запасы җитсен, ди!

Унсигез регион, федераль закон чыгуын көтмичә, мөмкинлекләренә карап, сугыш чоры балалары өчен нәрсәдер эшли башладылар. Кайдадыр пенсиягә өстәмә акча, транспорт өчен ташламалар булды, ә кемдер ЖКХ өчен 50 процент түләргә рөхсәт бирде. Татарстан, пенсионерларын сөендереп, нигәдер алдынгылар рәтенә басарга ашыкмый. Үзенең киң масштаблы проектлары белән дан тоткан нефть республикасының казнасында сугыш чоры балаларына бераз ярдәм итәрлек акча табылмас иде микәнни? Югыйсә күрше Самара өлкәсендә тапканнар бит. Монда бөтен эш... гаделсезлектә икән. Ике ел элек Дәүләт Советында бер депутат ханым белдерүенә караганда, әгәр дә бер субъект икенчесенә караганда күбрәк ярдәм итә икән, бу дөрес булмаячак. Бөтенесенә дә тигез булырга тиеш. Шуңа күрә өстән күрсәтмә көтәргә кирәк.

Ә өстән сигнал көткән арада, пенсионерларның тормыш дәрәҗәсе күз иярмәслек тизлек белән төшә бара. Ун меңлек пенсиянең өчтән бере фатир өчен түләүгә китә, тагын өчтән бере – даруларга. Нәтиҗәдә, халык мәнфәгатьләрен яклаучыларга ресторанда тамак ялгап чыгарга да тиеннәр генә кала... Бу гына җитмәгән, түземсезлек белән яңа закон көткән картларны әле алдарга да маташалар. Мәсәлән, узган ел Казанның Побежимов урамында Җиңүнең 70 еллыгына 1000 сум вәгъдә итеп, сугыш чоры балаларының исемлеген төзеп йөргәннәр. Хакимият бу мәгълүматны кире какты һәм кешеләрне уяу булырга чакырды – дошман йокламый, янәсе.

Дошман турында сүз киткән икән, элекке дошман турында да берничә сүз әйтеп үтик. Германиядә бала чагында Икенче Бөтендөнья сугышын кичергән һәркемгә – безнең акча белән аена 50 мең сум түләнеп бара.

Безнең илдә сугыш балаларының иң яшьләренә инде җитмештән артык. Чираттагы депутат тәкъдименә кадәр аларның күпмесе исән калыр, әйтүе кыен. Тик бу күптән көтелгән законның кабул ителү мөмкинлеге елдан-ел арта бара: льготага өмет баглаучыларның саны ел саен кими бит. Ә балачаклары сугыш уты белән өтелгән картларга өметләнеп көтәсе генә кала. Кайчандыр аларның ата-аналары Бөек җиңүне көткән кебек...

Людмила САФИУЛЛИНА








Василий **АЛЕКСАНДРОВ**



Игорь **КИЙКО**





• • •

Гороскоплар укырга яратам. Ул акча, сәяхәтләр һәм татлы мөнәсәбәтләр диңгезендә йөзә торган бердәнбер дөньям.

• • •

Ертык джинсылар, майкалар, футболкалар... Тишек носкилар модага кайчан керер икән?!

• • •

Рус теле һәм әдәбиятының яңа укытучысы:

— Балалар, әгәр кем дә булса берәрегез рус телен теләсә ничек идиомалар һәм килешмәгән ямьсез фразеологизмнар белән боза икән — белегез, шундук мордагызны ишәм!

• • •

Бер кыз юл кырыенда кул күтәреп басып тора. Бер машина туктый, йөртүчесе сорый:

— Кая барабыз?

— Миңа – шәһәргә.

— Яхшы, мин сезне рәхәтләндереп илтеп куям.

Кыз:

— Миңа рәхәте кирәкми, мин түләрмен генә.

• • •

Мин кайдандыр укыдым: табибларның изге-бөек җәфаланучысы һәм дәвалаучы Пантелеимоны бар икән. Әйтә алмыйм! Ярты көн буе табибка керергә чиратта тордым. Юк аларның бернинди изгеләре! Бөек җәфаланучысы бар — ул мин...

• • •

Рәсәйдәге юл йөрү кагыйдәләре хәрәкәтне җайлау өчен түгел, авария булган очракта гаеплене билгеләү өчен уйлап чыгарылган.

• • •

Ниһаять мин ял итәргә акчам булмаганга бармыйм, ә самолетлар очмаганга һәм террорлык куркынычы аркасында өйдә утырам.

• • •

Котлыйм! Нәселегезнең дәвамчысы туган икән!

— Мондый хезмәт хакы белән бернинди нәсел дәвамчысы булырга мөмкин түгел — балаларым булу гына мөмкин.

Марат **КАСЫЙМОВ**

ЧЫРА КАБЫЗЫП ЭЗЛӘСӘҢ ДӘ ЮК

“Бирәм дигәннең колына, чыгарып куя юлына”, диләрме әле? Миңа атап әйтелгән сүзләр, күрәсең! Телевизорны кабызуым була, шундук экранда элеккеге совет чорындагы тормышны чагылдырган фильмнарның хәзерге вариантына юлыгам. Алар әллә ни катлаулы булмаган сюжетка корылган; намуслы һәм талантлы баш геройга гэбэшниклар яки кабахәт төрләр белән парторглар каныга. Интектерәләр, эзәрлеклиләр һәм юньләп яшәргә ирек бирмиләр. Йә күңелне иркәли торган тавышлы җырчы Ободзинскийны үчеклиләр, йә итальян чибәркәенә гашыйк булган очучы-фронтовикның чыраен җимерәләр, инде хәзер арысланнарны өйрәтүче Маргарита Назарова ошамый аларга... Болар барысы да әйбәтләп төшерелгән — күренекле кешеләрнең тормышында чатаклык, ягъни “сылтау табып” яшеренгән — берничек тә бәйләнә алмыйсың! Ә бу “сылтауларда” никадәр ялган, ә күпме дөреслек — телевизор караучыбыз, эзләп карагыз!..

Карап туйгач, күз алдына әле күптән түгел булган күңелсез картина килеп баса: һәркайда мактанылган демократик үзгәртеп кору чорына хәтле гэбэшникларның һәм парторгларның әшәкелекләре һәм кыланмышлары чагыла.

Миңа, кызыксынып, өлкән буын кешеләре белән сөйләшергә туры килде. Аларның кайберләре министерствода эшләгәннәр, завод җитәкчеләре, газета редакторлары булганнар. Шуңа да карамастан, үз кул астында эшләүчеләр белән бергә сәхнәдә җырлаганнар, биегәннәр. Мин күп сораштырулар үткәрдем, алар мондый нәтиҗәгә китерде: сораштырганнарның берсе дә бер тапкыр да тере гэбэшникны күргәне булмаган, капиталистик илгә барыр алдыннан очрашканны искә алмаганда. Хәтта алар турында уйламаганнар да. Ә менә ОБХССны барысы да белгән. Хәзер генә ул чекистлар телеэкраннан төшмиләр, ә менә коррупциягә, хуҗасызлыкка һәм эшсезлеккә каршы көрәшүчеләрне яктыда чыра кабызып эзләсәң дә табып булмый.


Виктор **ФЁДОРОВ**



Илдар **НӘФИЕВ**



Валерий **ТАРАСЕНКО**





• • •

Физкультура дәресендә:

– Тәк, егетләр, кайсыгыз тарта? Тик дөресен әйтегез! Алдамыйча! Тәк, димәк, син... һәм син. Димәк, без тартып киләбез, ә калганнар – стадион тирәли биш тапкыр йөгереп килә!





ИНШАЛАР ӘСЫЕНТЫГЫ

Марксистлар дәүләтне халыкны талау инструменты дип санаган. Шуңа күрә дәүләт аларның башларын чапкан һәм Себергә урман кисәргә җибәргән.

Укытучы булырга теләмәс идем. Хәзерге балалар шулкадәр надан...

Хатын-кызларның хезмәт хакы үзләренә дә калырлык дәрәҗәдә булырга тиеш.

БМО трибунасыннан Хрущев америкалыларны хәтта Айда да «мочить итәргә» сүз биргән.

Көнбатыш безгә баш түгел, без хәтта үзебезнең хакимиятебезне дә һәрвакыт тыңламыйбыз.

Һәр ел саен ветераннарны Бөек Ватан сугышы белән котлыйбыз.

Илебездә венерик грамоталылык дәрәҗәсе үсә.


70 нче елларда СССРда дивидентлык хәрәкәте барлыкка килде.

Кешенең космоска очу нәтиҗәсендә, ниһаять Җирнең түгәрәк икәнен белдек.





Валентин ДРУЖИНИН



Антон МАКУНИ


НИНДИ КАБАХӘТ!..

— Букәев, кибеткә барырга кирәк!
— Инде йөгерәм, җаным!
— Букәев, ашарга әзерлә!
— Инде әзерлим, җимешем!
— Букәев, өйне җыештыр!
— Инде җыештырам, пескәем!
— Букәев, керләрне ю!
— Инде юам, сөеклем!
— Ә хәзер — үтүклә!
— Инде үтүклим, чәчәгем!
— Букәев, варенье кайнат!
— Инде кайнатам, куяным!
— Букәев, савыт-сабаны ю!
— Инде юам, фәрештәм!
— Букәев, миңа кофе китер!
— Китерәм, китерәм, акыллым!
— Букәев, хезмәт хакыңны китер!
— Бөтенесен дә ал, чибәрем!
— Кысып калганын да!
— Менә, алтыным!
— Букәев, ремонт ясарга вакыт!
— Инде ясыйм, кояшым!
— Ә хәзер, Букәев, инде мине сөйсәң дә була!
Өйдә тынлык.
— Букәев! Кайда син анда?
Тынлык.
— Букәев!
Тынлык.
— Үлгән… Нинди кабахәт, ә! Ә үзе яратам дип йөри иде…

Александр АЛЁШИН



Виктор БОГОРАД



Александр СЕРГЕЕВ





ӨСТӘМӘ КЕРЕМ

Элекке мәгариф идарәсе башлыгы Рафаэль Ганиев белән бергә бер төркем Әлмәт педагоглары күңелсез хәлгә эләккән. Төп эшчәнлекләреннән башка белем бирү әһелләре өстәмә керем алу ысулы уйлап чыгарганнар. Түгәрәкләр һәм секцияләр алып бару кебек нәрсәләр кәгазьдә генә калган – балалар аларны күрмәгәннәр дә. «Эшләп алынган» 800 мең сумның яртысы җитәкчеләр, тикшерүчеләр, кунакларның күңелен күрергә һәм алар өчен бүләкләргә тотылган. Бер өлеше – шәхси штрафлар түләргә, ә берникадәре экс-начальникнең үз мәнфәгатьләренә киткән. Намус дигән нәрсә дә педагог күңелләрен бөтенләй ташлап китмәгән – алар Кырымда яшәүчеләргә ярдәмгә 178 мең сум күчергәннәр. Бу «эшчәнлек» өчен «ширкәт» әгъзалары шартлы сроклар алган.

ТЫЙНАК ОСТА

Казаннан 38 яшьлек протез технигы Евгений В.ны республиканың иң тыйнак мошеннигы дип атарга була. Ике ел чамасы элек ул эшләгән фирма һәм хезмәт министрлыгы өч инвалид өчен протезлар әзерләү турында килешү төзиләр. Тик белгеч ясалма кул-аяклар ясап мәшәкатьләнергә теләми, һәм протезларны кабул итү-тапшыру актында картлар өчен имзаларны үзе куя. Фирма ялган документлар буенча 260 мең сум акча ала. Протез ясау остасына башкарылмаган эш өчен бу суммадан бары тик 10 мең сум эләгә. «Тыйнак» останың эше судка тапшырыла. Берни дә эшләп булмый – рухи сыйфатны протез урынына куеп булмый бит.

ИМГӘНҮ БӘЯСЕ

Кострома шәһәренең телефон компанияләренең берсенә үз хезмәткәрләре арасында спортны популярлаштыру ярыйсы гына кыйммәткә төшкән. Башкалардан калырга теләмичә, ул хезмәткәрләренең берсен Мәскәүгә – компаниянең намусын якларга җибәрә. Кострома егетенең ышанычлы сәләтләре юк дәрәҗәсендә булып чыга, һәм ул стартта ук бәйгедән төшеп кала. Киртә аша сикергән чакта ул уңайсыз егылып, табан сөяген сындыра һәм медаль урынына көчле имгәнү ала. Травманың «эш урынында» алынганлыгын «спортсмен»га суд аша исбатларга туры килә. «Казанышлары» өчен фирма сикерешчегә миллион сум тиеш дигән карар чыгара суд.

Вячеслав ШИЛОВ



Игорь ЛЕВИТИН



Гамир ХАНОВ

КАЙӘР СУККАН КӨННӘР

Бик күп бәла-казалар кичерде безнең ил. Түзде, сынмады, барчасыннан арынды һәм яңадан калыкты!

Ләкин соңгы чирек гасырдагы куркыныч шаукым хәтлесе булганы юк иде әле.

Иң элек Рәсәйне кавык каплады. Һәр ат шампунь флаконыннан, коры токмач кабыннан сибелә иде ул! Күрәбез, соңгы елларда Рәсәй аннан котылды, исеме дә ишетелми.

Рәхәтләнеп кенә яшисе дә бит, юк, илгә кариес ябырылды, кофе юшкыны тинтерәтергә тотынды. Тешләрен шыгырдатып түзде Рәсәй, авыр булса да чыдады һәм бу гарасатны да үткәреп җибәрде.

Юк икән: бөтен дөньяны чуалучан чәч проблемасы басты! Бөтен шәһәрләрдә, авылларда, тарлауларда, өйләрдә чәчләр кисешә-чуала башлады! Мәхшәр! Ләкин илебез моннан соң да исән калды.

Булмас димә, була икән шул! “Тегенди көннәр” бәла булып халкыбызны аптырашка калдырды. Телевизор каршында һәрбер утыручы элек белмәсә дә белде ул “көннәрнең” нинди икәнен — куркынычның куркынычы икән бит алар... Ләкин сабырлыгының чиге юк илебезнең — үтте “тегенди көннәр”.

Инде иркен сулыш алам дигәндә, менә сиңа мә: кабарыну афәте ябышты. моннан котылу авырның да авыры икән: бернәрсә дә ярдәм итми, аңа махсус таблеткалар кирәк, дәвалау ысуллары да башка. Әле һаман шул чир белән интегәбез, ай әшәке ул зәхмәт — сникерс та ярдәм итми. Әмма Рәсәй моннан да котылыр, Алла бирса!

Тик ул бернәрсәдән генә арына алмас — бәйләнчек һәм ахмак рекламадан. Менә монысы бәланең бәласе!

Игорь КИЙКО



Виталий ФЕОКТИСТОВ



Искәндәр БОРҺАНОВ

ДӘҮЛӘТ ПРОГРАММАСЫ

Җүләрләр белән көрәшү буенча Дәүләт программасы игълан итсәләр, шәп булыр иде.

Һәм аны игълан иткәннән соң, шунда ук кемнең моңа шатлануын, «ура» кычкыруын карап торырга да... аларның исемлеген төзергә.

Ә аннан соң җүләрләр белән көрәшү өчен бюджеттан чикләнмәгән финанслау таләп итәргә һәм бу тәкъдимгә кайсы финансистның нинди мөнәсәбәттә булуын теркәп куярга.

Җүләрләрне өйрәнү үзәге дә оештырырга кирәк. Анда бу мәсьәлә белән шөгыльләнергә теләгән бөтен акыллы кешеләрне җыярга һәм шулай ук исемнәрен мыекка чорнап куярга.

Депутатлар арасында җүләрләр белән көрәшүче оча, йөри һәм утыра торган төркемнәр булдырырга һәм аларга җүләрләр белән көрәшү турында Закон, кемгә, кайда көрәшү турында берничә төзәтмә әзерләргә кушарга. Ә моның белән шөгыльләнгәннәрне, әлбәттә, махсус яшерен исемлеккә кертергә...

Аннан соң, Закон белән каралганча, бу эшкә дәүләт чиновникларын тартырга һәм җүләрләр белән көрәш Идарәсе, регионнарда аның филиалларын булдырырга, аларга җүләрләрне табу һәм зарарсызландыру буенча инструкция төзүне йөкләргә...

Һәм, әлбәттә, контроль-тикшерү идарәсе оештырырга. Бөтен исемлеккә кертелгәннәрнең кайда, ничек көрәшкәнен тикшереп торырга...

Хәзер түбәндәге буын турында. Һәр предприятие, оешмада мәҗбүри рәвештә җүләрләр белән көрәш буенча урынбасар вазыйфасы кертергә.

Яшәү урынына карап җүләрләр белән көрәш буенча ирекле җәмгыятьләр булдырырга. Әгъзаларыннан ай саен взнослар җыярга, әлбәттә.

Аннан соң халык массаларына җүләрне тапкан һәм моның турында тиеш урынга хәбәр иткән кешеләргә өч дәрәҗәдәге күкрәк билгесе тапшырылачагы турында хәбәр итәргә.

Әлбәттә, беркем дә болай гына кеше җүләрләндеп йөрмәячәк. Моның белән махсус җүләрләр суды шөгыльләнергә тиеш.

Яшьләр турында да онытырга ярамый, урыннарда «Җүләрләр – без түгел» дигән хәрәкәт оештырып, анда кергән бөтен кешене резерв исемлегенә кертергә...

Көндәлек чараларны яктыртырга мәгълүмат чараларын җибәрергә, бу турыда журналларда язарга, күбрәк көлдерергә маташучы тапшырулар ясарга, һәм андагы бөтен катнашучыларны һәм алардан егылып көлүче тамашачыларны язып алырга...

Әлбәттә, исемлек төзүчеләрне дә онытмаска.

Ахыргы исемлекләр әзер булгач, бөтен исемлеккә кермәгәннәрне җүләрләр дип игълан итәргә.

Ә җүләрләр белән көрәш тәмамлангач, юллар белән нәрсәдер эшли башларга кирәк. Алайса алар җүләрләр белән көрәш барган арада, тагын безне каядыр читкә алып киткән...



КЫСАЛАР!..

Хәерле көннәр “Чаян” журналы хезмәткәрләре! Сезгә журналыгызны бик яратып укып баручы автор яза. Күңелле басманы күп еллар дәвамында укып барам, бер язылмый калганым юк. Соңгы вакытларда, заманалар катлауланып киттеме шунда, оптимист булып яшәве авырлаша бара. Элек, хан заманнарында да, олыларны һәм авыруларны рәнҗетмәскә тырышканнар. Хәзер исә хакимиятебез берни санламый, Алла да – бер, шайтан да. Менә тоттылар да мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларның фатирга түләү ташламаларын алып ташладылар. Ә нәрсә безнең белән санлашып торырга? Митингларга чыкмыйбыз, тавышгауга күтәрмибез, түрәләрнең күзләренә күренеп йөрмибез...

Күптән түгел дәүләтнең тагын бер кырын эше ачылды. Үземнең хикәям өчен йөз тәңкә гонорар алдым. Мине шундук эшләүче пенсионерлар исәбенә керттеләр. Баедың икән, пенсияңә бернинди дә өстәмә көтмә! Янәсе, “артыклыкка салым”...

Менә шулай мөмкинлекләре чикләнгән инвалид һәм пенсионерлар исәбенә таланган икътисадны торгызабыз...

Н. БАХТИНА

АРХАНГЕЛЬСК өлкәсе,
КОРЯЖМА

КӨНГӘ – 10 МЕҢ!

Хөрмәтле редакция! Пенсиямне “Ак барс” карточкасына күчерәләр. Җайлы да, рәхәт тә. Дөрес, банкоматка берничә тапкыр барырга туры килә. Акча күп булганнан түгел. Банк пенсия акчасын алуга лимит куйды. Тәүлеккә 10 меңнән артык алып булмый. Ә минем пенсиям — 11 мең! Лимитка сыеша алмаган бер мең артыннан икенче көнне барырга туры килә.

Банк бүлекчәсендә әлеге алым безнең файдага эшләнгән икәнен аңлаттылар. Картаның югалуы яисә аны урлаулары бар икән. Ул вакытта акчаны тулысы белән ала алмыйлар. Дәүләтнең шулхәтле кайгыртучанлыгына күздән яшьләр килерлек. Тик минем очракта һәм аз алучы пенсионерлар өчен бу алым артык дип саныйм.

Ә менә яртышар миллион ала торган пенсионерларга нишләргә (республикада андыйлар да бар икән)? Менә аларны чынлап та кызганам инде. Көнгә ун мең генә ала алгач, ничә көн чабасылары була бит банкомат янына, җанашларымның...

М. СӘГЫЙТОВА

ВАСИЛЬЕВО бистәсе,
ТАТАРСТАН









АЛЫМ ҖӘЛ ТҮГЕЛ СИҢА, ГУГЛ ҖӘЛ ТҮГЕЛ СИҢА…

Алар Интернет аша танышып өйләнештеләр һәм Интернет аркасында аерылыштылар.

Иң киң таралган вирус: «Әй, мин дөрес басмаганмын!» дип атала.

Шәп тә нәрсә инде скайп: кеше синдә кунакта, ә өстәл әзерләргә кирәк түгел.

Интернет барлыкка килү белән, кешелек йокысын югалтты.

Интернетка ялгау белән бергә, комплектта иярчен товарлар да сата башларга вакыт: күзлек һәм тузып тишелгән ыштан төбен ямау өчен энә белән тегәрҗеп.

Кайберәүләрнең эше һәм ялы Интернетка нинди компьютердан чыгуы белән генә аерыла.

Ринат АБЗАЛОВ

СӨЯРКӘ

Нишлим: үлеп гашыйк булды
Хатын асыл бер иргә.
Иртә-кичен, көнен-төнен
Үткәрәләр гел бергә.

Шартлар хәлгә җиттем инде
Янудан-көнләшүдән.
Минем якка күз дә салмый:
Файда юк әрләшүдән.

Бер минутка да җибәрми
Янынан ул иркәсен –
Интернет аша ярата
Виртуаль сөяркәсен.







Күренекле журналист
*Әгъзам **ФӘЙЗРАХМАНОВ** истәлекләреннән*

МУЛЛАЛАР ӘЗЕРЛӘҮЧЕ ПАРТОРГ

Бөтен мөселман дөньясында танылган дин әһеле Равил Гайнетдин үз вакытында Казан телевидениесенең яшьләр тапшырулары редакциясендә режиссер ассистенты булып эшләде, бер үк вакытта ул комсомол комитетының бюро әгъзасы да иде. Уйламаганда-көтмәгәндә Равил Бохара мәдрәсәсенә укырга китеп барды.

Бу хәбәр Казан телевидениесендә генә түгел, партия өлкә комитетында да аяз көнне яшен суккандай тәэсир ясады. Чөнки республикада мәчетләр ябылган, дини пропаганда тыелган чор иде. Мин ул вакытта Казан телевидениесенең партоешма секретаре идем. Ашыгыч рәвештә партия өлкә комитетының идеология секретаре Мөҗәһит Вәлиев чакырып алды. Исәнлек-саулык сорашып тормады. Сорауны кабыргасы белән куйды:

— Нәрсә дә булса уйларга сәләтлеме соң син? Башың бармы соң синең?

Аяк астыннан чыккан бу афәттән котылып булмаячагына килгәндә үк инанганлыктан, мин сүзне юморга борырга булдым. “Менә, бар бит”, — дип, башымны кулым белән сыйпап алдым.

Вәлиев исә мине тозлап-борычлап туйганчы сүкте дә, үз алдына сөйләнгәндәй әйтеп салды: “Беләсеңме син кем? Муллалар әзерләүче парторг”.

Әлбәттә инде, “коллективта һәм телевидение тапшыруларында атеистик тәрбияне үз агымына куйган өчен” миңа “строгий выговор” бирелде. Бу факт докладтан докладка күчеп, берничә ел иң югары мөнбәрләрдән яңгырады. Мөҗәһит Фәтхиевич секретарьлыктан киткәч кенә актуальлеген югалтты.

СИН ХОННЕКЕРНЫҢ ДУСТЫМЫ

Телевидениедә эшләгәндә иҗтимагый-сәяси тапшыруларның баш мөхәррире, бер үк вакытта партия оешмасы секретаре вазыйфасын башкарганлыктан, рәсми делегацияләрне каршы алу, озатып йөрү турында кинорепортажлар әзерләү бурычын миңа йөклиләр иде. Бервакыт Казанга ГДР җитәкчесе Эрих Хонеккер килде. Без, телевидениенең берничә хезмәткәре, алдан ук аэропортка килеп, самолетның кайда төшәчәген, трапны кую урынын ачыкладык. Операторга ярдәм күрсәтү максатыннан мин трап кырыена ук килеп бастым.

Шул вакыт һич көтелмәгән хәл булды. Хонеккер траптан төшүгә иң башта миңа кул бирде, кочаклап алды. Шуннан соң гына партия өлкә комитетының беренче секретаре Фикрәт Табеев һәм башка җитәкчеләр белән күреште.

Белмим, ГДР җитәкчесе мине кем дип исәпләгәндер, бәлки аның журналистларга мөнәсәбәте шундый булгандыр. Рәсми каршылаучылардан читтә, кинооператор кырыенда басып торган кешене аның республика җитәкчеләре белән бутавы, билгеле инде, мөмкин нәрсә түгел.

Берничә сәгатьтән эш бүлмәмдә ике КГБ хезмәткәре пәйда булды. Минем Хонеккер белән кайчаннан таныш булуым, Германиягә кайчан барып кайтуым белән кызыксындылар.

Эрнст ГЕЛЬМС, «Чаян» № 22, 1977



– Син, әйдә, терел тизрәк, синең пенсияңнән башка яшәп булмый!

Иван ХАНТИМЕРОВ, «Чаян» № 16, 1962



– Сезнең картинагыз фикер ачыклыгы һәм оригиналь чишелеше белән җәлеп итә...

СҮЗ ИЯРӘ – СҮЗ

Хәзерге табиблар кеше авырулары белән чиновниклар коррупция белән көрәшкән кебек көрәшә.

Карьера ясаганда баскычлар буйлап менәләр, култыкса буйлап төшәләр.

Гаилә драматургиясенең законы – актлар күбрәк булган саен, конфликтлар саны азрак.

Нәчәлствоның ахмак күрсәтмәләрен үтәү – кайчак саботаждан яманрак.

Алга киткән илләрдә үз проблемаларын тикшерәләр, артта калган илләрдә – алга киткәннәрнекен.

Кеше булыр идем, кешеләр бирми.

Һәр электрикның үз саклагыч фәрештәсе бар.

Кайчагында кеше белән уртак тел табу өчен, сүз әйтмичә калырга кирәк.

Вячеслав ШИЛОВ



Николай ВОРОНЦОВ



Рашат НИЗАМИ

ХӨРӘСӘН

Көн узсынга гына яшәп ята —
Акыл йоклый, кайнамый фикер.
Ике явыз черкине үтерде...
Көн үтте бит — Аллага шөкер!

МЧС

Шахта яки йортлар авып төшә,
Шәһәрләрне ташкын су баса...
Нишләр идек — илнең лабазында
Коткаручыларың булмаса?..

ӘЛӘКЧЕ

Тиреләре елтыр-елтыр,
Әйтерсең, хамелеон.
Гөнаһларын үлчәр өчен
Герләр кирәк — миллион!..

Хәмис ГАРИПОВ



МӘХӘББӘТ ТУРЫНДА

Менә тагын язлар җитте,
Мәхәббәткә тулды җиһан,
Пресса мәхәббәт турында
Кешеләрдән сораштырган.
Сораганнар бер егеттән:
“Баш иясең ни алдында?”
Егет горур җавап бирә:
“Бары мәхәббәт каршында!”
Сораганнар бер ир-аттан:
“Баш иясең ни алдында?”
Ир-ат уйлап җавап бирә:
“Бары мәхәббәт каршында!”
Сораганнар бер бабайдан:
“Баш иясең ни алдында?”
Бабай шундук җавап бирә:
“Бары әбиең каршында!”



ЧуАр пресса

КҮНЕГҮ ЯКИ ЯШӘҮ

Канадада яшәүче пенсионер Алан Вазеленчук Гиннесс рекордлар китабына эләккән. Ул 60 секунд эчендә йодрыкларында 91 мәртәбә иданнән этелгән. 65 яшендәге ир күп кенә яшьләрнең борынларына чиертә ала. Ә безнең пенсионерлар рекордны күнегү ясау буенча түгел, ә исән калу буенча куйдылар. 10 мең сум пенсия алып, яртысын коммуналь түләүләр биргәч, берәүнең дә калган калорияләрен күнегүләргә сарыф итү башына да килми.

ВАНДАЛЛАР ҺӘМ ПРЧИНДАЛЛАР

Франциянең Аркашон шәһәрендә Гераклның сыны тора. Бөтенесе дә яхшы, тик вандаллар даими рәвештә мифик геройның бер өлешен сындырып алалар. Һәр реставрациядән соң кемдер вандализм актын башкара. Шулай да шәһәр хакимияте бу четерекле хәлдән чыгу юлын тапкан – протез ясатканнар. Аны төнгә салдыралар, ә иртә белән урынына беркетеп куялар.

ПРОЦЕДУРАЛАР

55 яшьлек Сара Бердж үзенең гүзәл кыяфәтен саклау өчен 700 мең доллар тоткан. 150 пластик операция ясатканнан соң ул профильдә белем алган һәм үзенең Лондондагы фатирында косметик процедуралар уздыру өчен кабинет җиһазландырган.

Үзенең кыяфәтен һаман яхшыртырга теләү бәйлелеге барлыкка килгәч, Сара хәзер тышкы кыяфәтләре турында кайгыртучы хатын-кызларга яңа бит һәм гәүдә ясарга булыша.

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР

Хатыннар — музыкаль инструментлар кебек: аларның яңгырашы кемнең һәм ничек кагылуыннан тора.

Үз теләгең белән берәр нәрсә эшләп кара — икенче тапкыр синнән аны көтәчәкләр, өченче тапкыр — таләп итәчәкләр.

Әгәр хатын-кыз бай ирдән баш тарткан икән, димәк, ул кадәр үк бай түгел...

Әгәр хатын-кыз сезнең кубызга биеми икән, димәк, кубызыгыз юньле түгел.

Әгәр телевизордан атыш-куышлар, катастрофалар һәм кризис юк икән, димәк, сез реклама карыйсыз.

Тәҗрибәле хатын — ул тәҗрибәсез булып кылана белүче хатын.

Бөтен дөньяда – премиягә лаек булыр өчен; бездә генә премиядән мәхрүм итмәсеннәр өчен эшлиләр.

Хатыннар гына ике айлык хезмәт хакына алдан уйлый беләләр.

Әгәр акыллы да, җүләр дә бернәрсә әйтми икән, аларны бер-берсеннән аерып булмый.

(Зыялылар мәҗлесендә язып алынды)



Ринат МИРЗАЯНОВ

ШАЯРТМЫЙБЫЗ-КӨЛМИБЕЗ

ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

Хәбәр итәбез: икенче яртыеллыктан башлап «Чаян» ике тапкыр калынрак булып чыга башлаячак. Ике санны бергә кушып, журналны айга бер тапкыр чыгарырга карар кылынды. Айлык «Чаян» элеккечә сезнең тугры шаян дустыгыз булып калыр дип өметләнәбез!

Яңартылган «Чаян»га быелның 1 апреленнән үк язылырга була (бу шаярту түгел!).

Ә хәзер игътибар! Яраткан журналыгызны проблемаларсыз алыр өчен язылу тәртибендәге үзгәрешләргә игътибар итегез.

Татарстан укучылары аны «Почта России» каталогы, шулай ук онлайн https://podpiska.pochta.ru аша эшли алалар.


Бу очракта язылу индекслары татарча журналга П2438, ә русчасына П2440 булачак.

ОАО «Агентство «Роспечать» каталогында язылу индекслары элеккечә калды: 73488 – татар телендә, 73489 – рус телендә. Алар буенча Россия һәм Татарстан укучылары язылa ала.

«Чаян» өегезгә кояш булып балкып керсен!



Мирослав БАРТАК (Чехия)





• • •

Урамда берничә кеше берәүне кыйныйлар. Янәшәдән әби үтеп бара:

– Сез нәрсә дүртәүләп берәүгә ябыштыгыз, юньсезләр?

– Тик кенә тор, әби, без коллекторны тукмыйбыз!

– Нигә соң сез аны кулыгыз белән генә төясез? Аяк белән типкәләгез, кабахәтне, аяк белән!

• • •

Украина хөкүмәтенә карыйм да уйлыйм – менә кайда Чернобыль бәреп чыкты!

• • •

– Безнең тәрәзә каршында спорт кәчтүмнәре кигән кешеләр эче күренми торган пакетларга нәрсәләрдер тутыралар.

– Муеныңны сузып карама, тыныч кына утыр. Йә хәзер безне урлаячаклар яки урам чистартырга кушачаклар.

• • •

Мин бәләкәй чагымда урамнан песи баласы алып кайткач, әни әйтте:

– Үсәрсең, олы яшькә житәрсең, үзеңнең фатирың булыр – менә шунда ни апкайтсаң да ярар – хет кәҗә!

Юраганы юш килде...

• • •

– Кадерлем, син миннән айлар буе сердәшеңнеке шикелле туфли сорап интектердең! Менә, алдым, нигә кимисең?

– Аныкы төсле булганга!..

• • •

Бөтенесе нәрсә булса да сатып ала: кем яхта, кем вилла, кем футбол клубы... Мин ипигә барыйм әле!

• • •

Медицинаның мөмкинлекләре чиксез! Пациентларның гына мөмкинчелеге чикләнгән...

• • •

– Син үзеңнең хезмәт хакыңны ничек тотасың?

– 40% – ашауга, 50% – коммуналкага, 10% – киемгә, 20% – күңел ачуга һәм көтелмәгән чыгымнарга.

– Болай бит синең җәмгысы 120% килеп чыга!

– Бөтен бәла менә шунда шул...

Билл УАЙТХЭД (Бөекбритания)



Павел НОВОТНЫ (Словакия)





САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ

(СКОРПИОН)

№ 1 2016

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры һәм баш редактор Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ

Баш редактор урынбасары: **Ринат АБЗАЛОВ**

Баш редактор урынбасары, баш рәссам: **Александр АЛЁШИН**

Үсеш бүлеге: **Әдилә БАҺАВЕТДИНОВА**

Марс САБИРОВ

Җаваплы секретарь: **Гөлнара ЗАМАЛДЫНОВА**

Бүлек редакторлары: **Людмила САФИУЛЛИНА**

Артём СУББОТКИН

Алмаз ХӘМЗИН

Лилия ӘХМӘТОВА

Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Дизайнер: **Ләйсән ФӘЛӘХОВА**

УЧРЕДИТЕЛЕ: «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итүче Федераль служба (Роскомнадзор) идарәсендә теркәлде.

Теркәлү саны һәм вакыты: Эл № ФС77-61789, 18 май, 2015 ел.

Нәшер итүче: **АО «ТАТМЕДИА»**

Адрес: 420047 Казан, Академическая ур., 2

Редакция фикере авторлар фикере белән тәңгәл килергә мөмкин.

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

Реклама белдерүләренең дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.

Басма 16 яшьтән өлкәнрәк укучылар өчен чыгарыла.

«Чаян»нан икенен күрсәтмичә журнал әсәрләрен файдалану тыела.



татмедиа

Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, тел./факс: 222-05-54.

16+

E-mail: chayan@bk.ru

Сайт: chayan.su

Редакциянең адресы: Декабристлар ур., 2, ТР, Казан, 420066

Йолдыз ШӘРАПОВА

ЮБИЛЕЙ БҮЛӘГЕ

Яңа ел чыршыларының утлары сүнәргә өлгермәде, Алмаз Шәпи улының мәшәкате артты. Тиздән, бик тиздән туган көне җитә бит! Башка елларда үзен бер елга картайта, үлем белән якынайта дип уйлый торган мондый көнне бик өнәп бетермәсә дә, быелгысын үз итәргә әле исәбе. Чөнки монысы ни җитте генә түгел, түм-түгәрәк — юбилей! Үз гомерендә юбилейларның төрлесен күргәне бар инде аның, табын түрендәге юбилярлардан көнләшеп аз утырмады. Быел, Ходайның рәхмәте, теләкләр дә, бүләкләр дә аңа булачак. Алайса соңгы вакытта ул җитәкләгән бүлек гел арттагылар исемлегендә сөйрәлә, “Син җитәкче бит! Кая карыйсың?” — дип гел әрлиләр, гел сүгәләр үзен. Әйтерсең, дөньяның шулай үзгәрүенә, җинаятьчелекнең артуына һәм күбесенең ачылмыйча калуына бер ул гына гаепле. Рәхмәт инде юбилеена, бик вакытлы килеп җиткән, менә хәзер үзен төкерек чәчә-чәчә сүккән нәчәлнигы Тимур Роберт улы теш астыннан сыгып чыгарып булса да, мактамый кала алмас. Юбилейларда да, соңгы юлга озатканда да кешене яманларга ярамый ич. Бу — язылмаган канун. Аны бозарга берәүнең дә җөрьәт иткәне юк әле.

Юбилей тантанасы, алачак бүләкләр, үзен көткән мактаулар турында уйлап куйгач, Алмаз Шәпи улының кәефе тагын да күтәрелеп китте. Дөрес, мәшәкатьсез генә булмас инде бу юбилей дигәннәре. Зур-зур түрәләрне дә чакырырга туры килер. Түрәлек гомерендә нәкъ менә беренче чиратта өстәгеләргә ярарга кирәклеген төшенгән иде инде Алмаз Шәпи улы. Табын мәсьәләсен хәл ителде дип санаса да була. Узган ел бер ресторан директорының наркоман улын төрмәдән коткарып калган иде — шул директор хәзер аның алдында чәче белән җир себерергә дә әзер. Табынның менә дигәнен, кирәк булса күгәрчен сөтен дә табып куеп әзерләячәк. Ул затлы кунаклар зур-зур бүләкләр белән киләчәк инде, әлбәттә. Шуңа өстәл сыйдан сыгылып торырга тиеш булачак.

Бүләк дигәннән, Алмаз Шәпи улының үзенә күптәннән бер бүләк ясыйсы килә бит әле. Бүләк, дип, бик бүләк тә түгел бугай инде ул. Юк, нишләп бүләк булмасын, ди?! Бүләк һәм бүләкнең дә ниндие әле!

Беренче күрүдә үк ошатмады үзенең яңа хезмәткәрен Алмаз Шәпи улы. Кыланчыкмы, мактанчыкмы шунда, эш күрсәтергәме исәбе. Берлинны алырга барган кебек, дәртләнеп атлап йөрүләре үк эчен пошырды. Ләкин шулай булса да, эшкә алмый да булдыра алмады — егетнең рекомендациясе әйбәт иде. Алмаз Шәпи улының арттан сөйрәлгән бүлегенә шундый кирәк иде шул. Әйе, ул яшь белгеч чынлап та, тикшерү эше өчен махсус туган диярсең. Ул килгәч ачылган җинаятьләр саны күзгә күренеп артты. Бер яктан, Алмаз Шәпи улы моңа бүлеге өчен сөенсә дә, икенче яктан, өстәгеләр дә “чикләвекнең юкәдә икәнен” бик тиз төшенделәр. Телевизорда чыгыш ясарга да, газета-журналларга интервью бирергә дә Алмаз Шәпи улын түгел, шул эш сөючән яшь белгечне чакыра башладылар. Алмаз Шәпи улы икенче планга кала бирде. Әгәр берәр чарасын күрмәсәң, урынына менеп кунакларга да күп сорамас бу нәрсәкәй. Тизрәк котылырга кирәк моннан. Чөнки аның эшләмәве, бармакка бармак та сукмавы, көне буе компьютер каршында гына утыруы кара чалбарны ак җеп белән теккән төсле кычкырып тора башлаган иде инде. Менә шул кондәшен юк-бар сәбәп табып, эшеннән җибәрә алса, бу аның юбилееның иң шәп бүләге булачак. Шул кирәк аңа — йөрмәс бар дөнья эшләр-эшләмәс яшәгәндә берүзе генә ат кебек җигелеп тартып. Каян килгән хезмәт ударнигы. Алар теге гасырда калдылар бит инде.


Башына мондый юньле фикер килгәненә сөенеп, бу уен озакка сузмый гына тормышка да ашырды Алмаз Шәпи улы. Иртән иртүк көндәшен эштән азат итү турындагы приказы әзер иде инде аның. Йөгереп эшләп, яңа идеяләр белән янып йөргән талантлы яшь белгечнең бу хәбәргә кәефе төшсә дә, сер бирмәде. Ишектән чыкканда егетнең: “Тукайның “Баскыч” шигырен укыгыз!” — дигән сүзләре Алмаз Шәпи улының бер колагыннан керде, икенчесеннән шундый ук тизлек белән чыгып та китте. Алмаз Шәпи улы үз юбилеена үзе ясаган бу бүләгеннән бик канәгать, артык канәгать иде. Ул үзенең бөек җиңүен тантана итте. Чөнки нәчәлнигы Тимур Роберт улының да тиздән юбилее җитәсен һәм аның да Алмаз Шәпи улы кебек эшлексез җитәкчедән котылып, үзенә бүләк ясарга җыенуын бу вакытта белми иде әле ул... һәм белмәве белән бәхетле дә иде...

ЧАЯНВОРД

Уйна да, уйла да!

Ринат АБЗАЛОВ төзеде.

Язучы Газиз ...
Халык җыры
Самолёт
Композитор ... Бакиров
Артист, режиссер ... Зарипов
Батый ... (-1)
Шагыйрь ... Исәнбәт
Дөньялар ... Бульсын
Көнбатыш Африкадагы дәүләт
"... Апа" (халык җыры)
Капитал, акча
"Иртә дә торам..." (Г. Зәйнашева)
"Исле ..."
Нота
Таиланд иксәчә
"... Бураны"
Теркәү билгесе
Мизгел
"Давылдан соң дингез ... "
Надан
Бияләй
"... Егетләр" (Т. Миңнуллин)
Район үзәге (-2)
Җиденче нота
Кристиан нота
Сәнгать әсәрендә төп фикер
"... Логан" (автомобиль)
Артист ... Әхмәтҗанов
Американдагы дәүләт (аббр.)
Грек хәрефе
Шагыйрь Мөхәммәт ...
Ток көчен үзгәртү җайланмасы, резистор
Диңгездә давыл
Халык ... чапты
"Ир канаты ... була"
Язгы ...
Шагыйрь ... Зәлкарнәй
"Агыйделдә ике ..."
Океан ... җырчы Ильясов



ТАБЫШМАК БИЛ АЛЫШМАК

1. Вампирлар кайсы яклары белән яхшы?

2. 30 яшьтәге хатын-кызның 30 дан соңгылары белән аермасы?

3. Рәсәйдә түләүсез медицина бармы?

4. Ничек итеп хезмәт хакын икеләтә арттырып була?

5. Начальник кем ул?

6. Хатын-кыз һәрвакыт дөрес. Ни өчен?

7. Дәвалау серләрен табиблар ничек ути?

ЖАВАПЛАР

1. Алар җылы тәхеткә үрмәләмиләр. 2. Утыздан соң хатын-кыз бик кыланмый, чөнки инде ул бу яшьтән соң әллә ни кыра алмый. 3. Бар. Елена Малышеваның телевизион тапшыруы. 4. Акчаларыгызны көзге каршына куегыз. 5. Шундый кеше — син соңга калып килгәндә, ул эштә; һәм син иртүк эштә утырганда, ул әле күренми дә. 6. Чөнки. 7. Таракан йөргән кебек язып.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда ике җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 7 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзләре – **«ТУГАН ТЕЛ», «САКМАР».**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Ә. ГАРИПОВА (Әлки р-ны, Иске Салман ав.),
Р. ЙОСЫПОВ (Арча р-ны, Яңа Кишет ав.),
Р. ИШМОРАТОВ (Арча р-ны, Урта Сәрдә ав.),
М. МИҢНЕМУЛЛИНА (Балтач р-ны, Норма ав.),
Д. НУРГАТИНА (Алексеевский р-ны, Урманасты Шонталасы ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).


Җиңүчебез – Казаннан
Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛИН!

СӘЕР КЕШЕЛӘР

Валентин ДУБИНИН



Владимир СОЛДАТОВ



Николай ВОРОНЦОВ



Валерий ТАРАСЕНКО

